# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында"**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 12 мартында
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында" 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2009, 19 декабрь; 2010, 1 гыйнвар, 16 гыйнвар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6) Россия Федерациясе гражданлыгы юкка чыгуга, чит ил гражданлыгын алуга йә яшәүгә рөхсәт яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган бүтән документ алуга;";

2) 13 статьяның 4 өлешендәге беренче җөмләсендә "1 пункты нигезендә билгеләнгән картлык буенча хезмәт пенсиясенең биш база өлеше" сүзләрен "картлык буенча хезмәт пенсиясенең 2 пункт нигезендә билгеләнгән иминият өлешенең бишләтелгән беркетелгән база зурлыгы" сүзләренә алмаштырырга;

3) 15 статьяның 2 өлешендәге беренче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын кимендә 15 ел биләгән йә шушы вазыйфаларны өч елдан артыграк биләгән һәм дәүләт хезмәте стажы барлыгы кимендә 15 ел булган затларга пенсиягә өстәмә Татарстан

Республикасының тиешле дәүләт вазыйфасы буенча исәпләнгән айлык акчалата гомуми түләүнең 80 проценты күләмендә билгеләнә.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 5 апреле
№ 15-ТРЗ